**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

**2022 елның 10 июне** **1436 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге Советының 2002 елның 18 маендагы 37-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында.**

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженерлык, транспорт, социаль һәм торак инфраструктурасын үстерү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 14 октябрендәге 13-РС номерлы карары белән расланган, кадастр номерлары 16:24:110302:125016:24:110302:1247;16:24:110302:1518;16:24:110302:1519;16:24:110302:1397 16:24:110301:1015 булган җир кишәрлекләрен индивидуаль торак төзелеше өчен Травкино авылы һәм Хәерби авылы торак пункт чикләренә кертүне, кадастр номеры 16:24:110301:577булган җир кишәрлегенә - «Сәнәгать җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге» категориясен билгеләүне күздә тоткан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.

2. Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты материалларының түбәндәге составын билгеләргә:

1) территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә;

2) җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасы;

3) җирлек составына керүче торак пунктларның чикләре картасы;

4) җирлекнең функциональ зоналары картасы;

5) Торак пунктларның үзгәрүче чикләре урынының график тасвирламасы, әлеге чикләрнең координаталары исемлегендә күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координаталар системасында күрсәтелгән җирлек составына керүче торак пунктлар чикләре турында белешмәләр;

6) Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын нигезләү материаллары.

3. Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын әзерләү 100% күләмендә инвестор хисабына башкарылачак, башкарылган эшләр өчен түләү аларны үтәү факты буенча башкарылачак дип билгеләргә.

4. Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләренең түбәндәге

этапларын билгеләргә.:

| Этап номеры | Эшләр этабы исеме |
|---|---|
| 1 | Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә контракт төзү |
| 2 | Проектны әзерләү |
| 3 | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында үзгәрешләр кертү проектын килештерү |
| 4 | Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын раслау өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрү |

5. Генераль планны әзерләү эшләрен оештыруны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.

6. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Җитәкче** **А.А. Новиков**